**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«28» ноябрь 2018 ел** **№ 336**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Азнакай звеносы турында» 2016 елның 11 ноябрендәге 321 номерлы Карары (2017 елның 29 ноябрендәге 299 номерлы карар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасы муниципаль звеносы турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 30.12.2003 ел, №794 «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасы турында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 18.07.2018 ел, №840 «гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Азнакай звеносы турында» 2016 елның 11 ноябрендәге 321 номерлы Карары (2017 елның 29 ноябрендәге 299 номерлы карар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының Муниципаль звеносы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

1.1. 21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Азнакай муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Азнакай звеносының төп чаралары булып түбәндәгеләр тора:

а) көндәлек эшчәнлек режимында:

- әйләнә-тирә торышын өйрәнү, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерергә мөмкин куркыныч табигать күренешләренә һәм техноген процессларга мониторинг үткәрү, гадәттән тыш хәлләрне фаразлау, шулай ук аларның социаль-икътисадый нәтиҗәләрен бәяләү;

- халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат җыю, эшкәртү һәм алмашу;

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча максатчан һәм фәнни-техник программаларны, чараларны эшләү һәм тормышка ашыру;

- Азнакай районы ТП РСЧС идарә органнары һәм көчләре гамәлләрен планлаштыру, аларның эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү;

- халыкны гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә, шул исәптән ашыгыч хәбәр итү сигналлары алгач үз-үзеңне ничек тоту кагыйдәләренә өйрәтү; хәрәкәтләргә әзерләү;

- халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә белемнәрне пропагандалау;

- гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурслар резервларын булдыру, урнаштыру, саклау һәм тулыландыру белән җитәкчелек итү;

- халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә үз вәкаләтләре чикләрендә дәүләт экспертизасы, күзәтчелек һәм контроль үткәрү;

- үз вәкаләтләре чикләрендә кирәкле иминият төрләрен гамәлгә ашыру;

- куркынычсыз районнарга халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне эвакуацияләүгә әзерлек, аларны урнаштыру һәм даими яшәү яки саклау урыннарына кайтару, шулай ук халыкны гадәттән тыш хәлләрдә тормыш белән тәэмин итү буенча чаралар үткәрү

- гадәттән тыш хәлләр турында статистика хисабын алып бару, аварияләр һәм һәлакәтләрнең сәбәпләрен тикшерүдә катнашу, шулай ук мондый аварияләрнең һәм һәлакәтләрнең сәбәпләрен бетерү буенча чаралар эшләү;

б) югары әзерлек режимында:

-әйләнә-тирәнең торышына контрольне көчәйтү, гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуга китерергә сәләтле куркыныч табигать күренешләренә һәм техноген процессларга мониторинг үткәрү, гадәттән тыш хәлләрне фаразлау, шулай ук аларның социаль-икътисадый нәтиҗәләрен бәяләү;

- Азнакай район звеносының идарә органнары җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары тәүлек буе идарәнең стационар пунктларында  территориаль пунктларында кизү торуларын кертү;

- Азнакай район звеносының  идарә органнары тарафыннан гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүматларны өзлексез җыю, эшкәртү һәм тапшыру, гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү;

- гадәттән тыш хәлләр килеп чыгуны һәм үсешен кисәтү, барлыкка килгән очракта зыян күләмен һәм югалтуларны киметү, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен һәм иминлеген арттыру буенча оператив чаралар күрү;

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планнарын һәм башка документларны аныклау;

- Азнакай районы звеносының  көчләре һәм чаралары кирәк булганда гадәттән тыш хәлләргә җавап бирергә әзер булу, оператив төркемнәр формалаштыру һәм аларны алдан фаразланган районнарга чыгаруны оештыру;

- гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен булдырылган матди ресурслар резервларын тулыландыру;

- эвакуация чараларын үткәрү;

в) гадәттән тыш хәл режимында:

- әйләнә-тирәлек торышын өзлексез контрольдә тоту, барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр үсешен мониторинглау һәм прогнозлау, шулай ук аларның социаль-икътисадый нәтиҗәләрен бәяләү;

- федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар җитәкчеләренә, шулай ук барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итү;

- халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чаралар үткәрү;

- Гадәттән тыш хәлләрне бетерү һәм Азнакай район звеносының көч һәм чараларының эшен төрле яклап тәэмин итү, аларны үткәрү барышында җәмәгать тәртибен саклау, шулай ук билгеләнгән тәртиптә иҗтимагый оешмаларны һәм халыкны гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә җәлеп итү буенча эшләрне оештыру;

- гадәттән тыш хәлләр зонасында һәм аны бетерү буенча эшләрне үткәрү барышында өзлексез җыю, анализ һәм мәгълүмат алмашу;

- гадәттән тыш хәлләрне бетерү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары һәм оешмалар администрацияләре арасында өзлексез хезмәттәшлекне оештыру һәм тәэмин итү;

- халыкның гадәттән тыш хәлләрдә яшәешен тәэмин итү буенча чаралар үткәрү;

- халыкка гадәттән тыш хәлләр, аларның параметрлары һәм масштаблары, халыкның һәм территорияләрнең иминлеген тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар, саклану алымнары һәм чаралары, гамәлләр тәртибе, гадәттән тыш хәл зонасында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм зыян күрүчеләрне социаль яклау өлкәсендә гражданнарның хокуклары турында, шул исәптән Россия Федерациясе законнарында каралган түләүләрне алу хокукы турында, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә югалган документларны торгызу тәртибе турында мәгълүмат бирү.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов